**Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы**
**дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре | № 270-32 | «28» март 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2022 елның 12 октябрендәге 171-19 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (14.12.2022 №188-20, 18.04.2023 №208-24, 25.10.2023 №241-27, 14.12.2023 №255-29 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай районы Советының 2022 елның 12 октябрендәге 171-19 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә (14.12.2022 №188-20, 18.04.2023 №208-24, 25.10.2023 №241-27, 14.12.2023 №255-29 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 6 статьяның 5 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11.2 пунктчаны өстәргә:

«11.2) «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр, аларга федераль бюджет акчалары (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) капиталь кертемнәрне финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы төзи;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo. tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис | М.З. Шәйдуллин